Магариф - 2002 - № 6 - С. 71

*Мирзанур Вәлиев*

**Педагогикада – яңа төшенчәләр**

Педагогик әдәбиятта, газета-журнал материалларында соңгы елларда кулланылышка кереп килүче төшенчә-терминнар шактый күп очрый (бу бигрәк тә рус һәм чит ил телләреннән тәрҗемә ителеп яки алардан файдаланып язылган материалларда шулай). Аларны аңлау еш кына кыенлык тудыра. Шуңа күрә әлеге төшенчәләрнең кайберләренә кыскача аңлатма биреп, кулланылыштан мисаллар китерәбез. (Мисал-җөмләләр «Татарстан Республикасы мәгарифенең милли доктрина-сы»ннан («Мәгърифәт», 17 март, 2001 ел) алынды.

Мәгариф хезмәткәрләренең статусы.

«Статус» – кешенең җәмгыятьтәге урыны, хокукый хәле дигән сүз.

«Мәгариф хезмәткәрләренең статусы» дигәндә, бер яктан – аларның иҗтимагый функциясе (балаларга һәм яшьләргә үткән буыннар туплаган белем һәм күнекмәләрне, рухи-әхлакый кыйммәтләрне тапшыру; яшь буынны мөстәкыйль эшчән-леккә әзерләү), ә икенче яктан–аларның җәмгыятьтәге абруе, социаль роле аңлатыла.

(Шунысында искәртеп үтик: соңгы вакытларда анкеталар тутырганда «статус» дигән пункт очрый, бу очракта ул русча «должность» дигән сүз белән тәңгәл килә диярлек.)

«Укучыларның һәм мәгариф хезмәткәрләренең абруен һәм социаль статусын даими күтәрү өчен шартлар тудырырга» (Доктринадан.)

Инновацион технологияләр.

Innovation – инглизчә «яңалык» дигән сүз. «Инновацион технологияләр» дигәндә, укыту һәм тәрбия эшләрендә чагыштырмача күптән түгел кулланыла башлап, нәтиҗәлелеге ягыннан үзен аклаган методика һәм эчтәлек күздә тотыла. «Технология» һәм «методика» сүзләре мәгънә ягыннан якын; «технология» төгәл билгеле нәтиҗәгә юнәлтелгән метод һәм ысуллар чылбырын тәшкил итә.

Педагогик инновацияләр яңача фикерләү, фәндә, техникада, җитештерүчән хезмәттә яңа ачышлар белән бәйле.

Әлеге төшенчәнең хәзерге вакытта гаять киң кулланылуын истә тотып һәм аның эчтәлеген ачып бирү максатында, педагогик инновацион технологияләрнең кайбер төрләрен атап үтик:

интеграцияләнгән укыту – педагогик процесс яки дәрес төрле фәннәр эчтәлеген берләштереп үткәрелә;

дәрес-панорама–өйрәнелә торган объектны (мәсәлән, географиядән – берәр илне) төрле яклап тасвирлау;

дәрес-блок– берничә гадәти дәресне эченә ала (лекция, мөстәкыйль эшләү, гамәли эш башкару, белемнәрне тикшерү);

адаптацияләнгән (җайлаштырылган) укыту – эчтәлекне, форма, ысул, алымнарны укучыларның үсеш дәрәҗәсенә һәм үзенчәлекләренә, белем дәрәҗәсенә яраклаштырып, җайлаштырып, үзләштерә алырлык итеп укыту; яки: «милли төбәктә (социаль-икътисадый, этник-мәдәни, демография һ. б. якларны истә тотып) яраклаштырылган белем бирү системасы..."(Доктринадан.)

Уку-укытуны оптимальләштерү– балаларның мөмкинлекләренә туры килә торган иң уңайлы шартлар булдырып укыту;

активлаштыру– укучыларның белем алу эш-чәнлеген көчәйтү, кызыксындыру;

дифференцияләйттерелгән укыту–укучылар-ның сәләтләрен, мавыгу-кызыксынуларын искә алып, апарны төркемнәргә бүлеп белем бирү;

педагогик аралашу, хезмәттәшлек – педагог һәм укучы, педагог һәм ата-ана, педагог белән педагогның үзара бәйләнеше, аралашуы, килешенеп эш итүе.

(Карагыз: Габдуллин Г. Г, Хуҗиәхмәтов Ә. Н. Педагогик сүзлек.– Казан, 1997.)

Соңгы елларда милли, дини мөнәсәбәтләр активлашу, күпмәдәниятлелек, идея-инанулар төрлелеге шартларында толерантлык төшенчәсе кулланылышка керә башлады, ул – «сабырлык», «түземле мөнәсәбәттә булу», «татулык» дигән сүз». Педагогикада ул – тәрбиянең бер юнәлеше («толерантлык тәрбияләү, формалаштыру, үстерү»). Инглиз теленнән кергән әлеге термин tolerance татарчага «түзеп торырлык»; «түземле», «сабыр» дип тәрҗемә ителә. Шулай ук аны бер-береңә юл кую, ирек бирү, һәр кешенең үз фикерләрендә калуы дип аңлау да дөрес була.

Белем бирүне информатизацияләү–хәзерге заман мәгълүмат (информация) чараларыннан (компьютер, интернет, радио, телевидение һ. б.) белем бирү, мәгариф белән идарә итү максатларында файдалану, шул чараларны укыту-тәрбия процессына кертү, моңа мәгариф хезмәткәрләрен әзерләү, кирәкле техник җиһазлар булдыру дигән сүз.

«... Мәгарифне киң күләм информатизацияләү». (Доктринадан.) Шунда ук: «...мәгарифтә информацион технологияләрне тормышка ашыручы программалар төзү».

Академик мобильлек. «Мобильлек» («мобильность») хәрәкәтчәнлек, бер даирәдән икенчесенә чагыштырмача җиңел күчә алу мәгънәсенә ия. Белем алуда хәзер «китапка ябышып яту» түгел, ә төрле мәгълүмат чараларыннан файдалану, хәтта берьюлы берничә уку йортында шөгыльләнү, өлгерлек, җитезлек («Белемне ул кайда бар, шуннан алырга ярый») уңай бәяләнә.

«...Укучыларның академик мобильлегенә ирешү». (Доктринадан.)

Укыту-тәрбиянең шәхес үстерүгә юнәлтелүе

(«личностно-ориентированное обучение»)–хәзерге педагогика фәнендә халыкара танылу алган һәм уңай бәяләнә торган юнәлеш. Ул, укучының сәләтен, мөмкинлеген, белем-күнекмәләрен, теләк-омтылышларын истә тотып, белем-тәрбия бирүгә, балаларга гуманлы, таләпчән, оптимистик мөнәсәбәтләрдә булуга нигезләнә.

«... Белем бирүнең гуманистик, дөньяви характерда булуы, аның укучы, социаль яктан мохтаҗ катлам мәнфәгатьләренә, танып-белү ихтыяҗларына җавап бирүе, укыту-тәрбия процессының шәхес үстерүгә юнәлтелүе».

«–... шәхеснең белемгә ихтыяҗын, индивидуаль үзенчәлекләрен (этнографик якны да) искә алып, шәхеснең үсүенә ориентлашкан укытуны булды ру». (Доктринадан.)

Педагогиканың төшенчәләрендәге яңалыклар, аларның исемнәре генә түгел, җисемнәре дә тормышта урын алуы алгарыш дәрәҗәсен, юнәлешләрен күрсәтә. Фәнни әдәбиятта кулланылып та, мәгариф хезмәткәрләренең киң даирәсенә билгеле булмаган термин-төшенчәләрнең аңлатмалы сүзлекләрен эшләү һәм мәктәпләргә, башка уку йортларына җиткерү зарур.